| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЕЛАБУЖСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛАБУГА<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 24.08.2023 1244 КАРАР

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2011 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме,шул исәптән социаль контракт нигезендә күрсәтү турында» 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында һәм Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарында кадрлар үзгәрешләре белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2011 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертеп, яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта).
2. Алабуга муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
3. Алабуга муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссиясенең утырышлар графигын расларга (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары Р.А. Мусаевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
24.08.2023 1244 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссиясе составы**

1. Мусаев Р.А. - Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадb үсеш буенча урынбасары;
2. Прохорова С.В. – социаль һәм башка төр тәэмин итү төркеме башлыгы урынбасары, Алабуга муниципаль районындагы МТЗ һәм СЗ социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча)
3. Десятова Л.Ф. - АМР ТР МТЗ һәм СЗ «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» ДАУСО гаиләгә һәм балаларга ярдәм итү бүлеге мөдире (килешү буенча);
4. Чернышева И.Р. – «АМР ТР МТЗ һәм СЗ «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» ДАУСО директоры (килешү буенча);
5. Демина Ю.Л. – Алабуга муниципаль районында Халыкның хезмәт һәм мәшгульлек үзәге директоры (килешү буенча);
6. Шантурова А.К. – Алабуга муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы;
7. Деготькова Г.Р. – «АМР мәгариф идарәсенең» МКУ тәрбия эше һәм өстәмә белем бирү методисты;
8. Порсев Г.В. – «АҮРХ» ССДАУ поликлиника эше буенча баш табиб урынбасары (килешү буенча);
9. Бочарова Е.Е. -АМР Башкарма комитетының икътисад тармакларын анализлау, фаразлау һәм үстерү бүлегенең баш белгече;
10. Косов А.В. – Алабуга муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча).
11. Галимова М.Б. - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү секторы мөдире.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
24.08.2023 1244 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районындагы социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә**

1. Социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү буенча ведомствоара комиссия (алга таба - Ведомствоара комиссия) гражданнарның авыр тормыш хәлендә калган мөрәҗәгатьләрен һәрьяклап һәм объектив карау, гражданның һәм (яисә) аның гаиләсенең авыр тормыш хәленнән чыгуы буенча килештерелгән чаралар эшләү максатларында төзелә һәм коллегиаль орган булып тора.

2. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтүгә бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссия (алга таба – ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме,шул исәптән социаль контракт нигезендә күрсәтү турында» 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карарына ярашлы рәвештә төзелде.

3. Ведомствоара комиссия рәисе булып Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары тора.

Ведомствоара комиссия әгъзалары булып муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, опека һәм попечительлек органнары, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль яклау, гаиләгә һәм балаларга һәм башка оешмаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәге (бүлекчәсе) вәкилләре тора.

5. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең һәм муниципаль учреждениеләрнең, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан башка оешмаларның авыр тормыш хәлендә калган затларга гамәлдәге законнар нигезендә адреслы социаль ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

- граждан тарафыннан кабул ителә торган үзара йөкләмәләр нигезендә гражданның һәм (яисә) аның гаиләсенең авыр тормыш хәленнән чыгу өчен шартлар тудыру.

5. Ведомствоара комиссия түбәндәге бурычларны хәл итүгә хокуклы:

- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларын һәм белгечләрен, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан оешмалар вәкилләрен ведомствоара комиссия утырышларына чакырырга;

- федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материаллар һәм мәгълүмат соратып алырга;

- авыр тормыш хәлендә калган гражданнарны ведомствоара комиссия утырышларына чакырырга, аларның аңлатмаларын тыңларга;

- гражданнарга гамәлдәге законнар һәм бюджет йөкләмәләре лимиты кысаларында гражданның һәм (яки) гаиләнең авыр тормыш ситуациясеннән чыгуына юнәлдерелгән чаралар турында фикер алышырга һәм тәкъдим итәргә, аларны үтәү үзара йөкләмәләр турында социаль контрактта беркетелә;

- Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан башка оешмаларга гражданның һәм (яисә) аның гаиләсенең авыр тормыш хәленнән үз вәкаләтләре чикләрендә чыгуы буенча чаралар күрергә тәкъдим итәргә;

- гамәлдәге законнар нигезендә. Алабуга муниципаль районындагы «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге» ДАУСО белгече тарафыннан үзара йөкләмәләр турында социаль контрактта беркетелгән шартлар һәм йөкләмәләр үтәү буенча тикшерү билгеләргә6. Ведомствоара комиссия рәисе ведомствоара комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә, ведомствоара комиссия утырышларын уздыру датасын һәм вакытын билгели.

7. Ведомствоара комиссия утырышлары гариза биргән көннән алып 10 (ун) көн эчендә уза.

8. Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларның гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса тулы хокуклы санала.

.9. Комиссиянең һәр утырышы алдыннан тулы хокуклы булуын билгеләү өчен Комиссия әгъзаларын теркәү уздырыла.

10. Ведомствоара комиссия карарлары ведомствоара комиссия әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, ведомствоара комиссия рәисе тавышы хәл иткүче булып тора.

11. Ведомствоара комиссия карарлары ведомствоара комиссия рәисе имзалаган протокол белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
24.08.2023 1244 номерлы
карарына 3 нче кушымта

**Алабуга муниципаль районында социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәме күрсәтү белән бәйле мәсьәләләрне карау буенча ведомствоара комиссиясенең утырышлар графигы**

Үткәрү урыны: Алабуга шәһәренең «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге, Городищенская урамы, 4 нче йорт

Үткәрү вакыты: 13.30 сәгать (һәр атнаның пәнҗешәмбе көне )